БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

«26» 07 2023 ел

№ 197

Бинаны торак йорт,торак йортны яшәү өчен яраксыз,күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиеш дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында» 2019 елның 19 апрелендәге 167 номерлы һәм «Җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2022 елның 8 апрелендәге 174 номерлы карарлары нигезендә Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Бинаны торак йорт,торак йортны яшәү өчен яраксыз,күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиеш дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең беркетелгән административ регламентын расларга

2. Гамәлдән чыккан дип таныргa:

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2022 елның 21февралендәге «Бинаны торак йорт,торак йортны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиеш дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарын;

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 18 гыйнварындагы 29 номерлы карарының 2 пунктындагы алтынчы абзацы.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач

муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
Җитәкчесе

А. Ф. Хәйретдинов